**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МАМЫКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**МАМЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Мамык авылы **КАРАР**

**9 гыйнвар 2020 ел** **№ 1**

**2020 елга мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза бирелә торган мәҗбүри эш төрләрен һәм оешмалар исемлеген билгеләү турында**

«Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан мәҗбүри эш төрләрен һәм оешмалар исемлеген билгеләү турында» 2012 елның 16 ноябрендәге ПР-43-6 номерлы (2012 елның 8 июнендә административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе Кодексына кертелгән үзгәрешләр белән бәйле рәвештә) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы Президиумы карарын үтәү йөзеннән мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза билгеләнгән затларны төзәтү, аларда нормаларга, җәмгыять кагыйдәләренә, иҗтимагый-файдалы хезмәткә карата ихтирамлы мөнәсәбәт формалаштыру максатларында, административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 32.13 статьясы нигезендә, һәм, законлы көченә кергән суд карары буенча административ җәза үтәү рәвешендә башкарылучы мәҗбүри эшләрнең Мамык авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри хезмәт булып саналуын исәпкә алып, Мамык авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Хөкем ителүчеләргә мәҗбүри яки төзәтү эшләре рәвешендә җәза үтәү өчен түбәндәге мәҗбүри һәм төзәтү эшләре төрләрен билгеләргә:

- Территорияне төзекләндерү, чистарту, яшелләндерү, җир казу эшләре, юлларны һәм башка тышкы төзекләндерү объектларында башкарылучы эшләр.
- Территорияләрне санитар чистарту.
- Төяү-бушату эшләре.

Алдан һәм һөнәри әзерлекне таләп итми торган хезмәт эшчәнлегенең башка төрләре, җинаять башкарма инспекциясе белән килешү буенча.

2. “Мамык авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәү өчен объект итеп:

- Мамык авыл җирлеге администрациясен билгеләргә.

3. “Мамык авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә төзәтү эшләре рәвешендә җәза үтәү өчен өчен объект итеп:

- Мамык авыл җирлеге администрациясен билгеләргә.

4. Әлеге карарны Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Нурлат районы буенча филиалына Мамык авыл җирлеге территориясендә яшәүче төзәтү яки мәҗбүри эшләргә хөкем ителгән затларга карата суд карарларын берлектә үтәтүне тәэмин итү өчен җибәрергә.

5. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда һәм «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтта урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Мамык авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе В.В.Рыжков